# БАЛАЛАРГА
# ЙӨЗ ДӘ БЕР СОРАУ

**1) Иманның рөкеннәрен әйт.**

Җавап: Аллаһка иман, Аның фәрештәләренә иман, Аның китапларына иман, Аның пәйгамбәрләренә иман, ахирәт көненә иман, һәм тәкъдиргә иман.

**2) Пәйгамбәребезгә беренче вахи иңгәндә ничә яшь иде?**

Җавап: 40

**3) “А” хәрефенә башланган иң бөек затны әйт!**

Җавап: Аллаһ.

**4) Ике төрле күзгә Җәһәннәм уты кагылмас, әйтеп бир?**

Җавап: Аллаһтан куркып елаган күз һәм Аллаһ юлында йокламыйча сакта торган күз.

**5) Җир йөзендә иң имин җир кайда?**

Җавап: Мәккәдә.

**6) Исламның рөкеннәрен әйт.**

Җавап: 1) “Лә иләһә илләАллаһ, Мөхәммәд расүлАллаһ” – дип таныклык бирү, 2) намаз торгызу, 3) зәкәт бирү, 4) Рамазанда ураза тоту, 5) хаҗ кылу.

**7) Күренекле сахәбә Әбү Һүрайраның исеме ничек?**

Җавап: Габдуррахмән бин Сахр әд-Дәүсий.

**8) Җөмләне дәвам ит: Аллаһ кешене ...**

Җавап: иң яхшы сурәттә халикъ кылды.

**9) Мөселман ашый башлар алдыннан нәрсә әйтә?**

Җавап: Бисмилләһиррахмәниррахим

**10) Курайш кабиләсе кышын һәм җәен кайсы якларга сәфәр иткәннәр?**

Җавап: кышын – Йәмәнгә, җәен – Шәмгә.

**11) Пәйгамбәребезнең ятаганда йоклаган сахәбәнең исеме ничек?**

Җавап: Гали бин Әбий Талиб.

**12) Синең 55 сум акчаң бар иде, шуларның 20 сумын бер фәкыйрьгә садака итеп бирдең. Ничә сум акчаң калды?**

Җавап: 35

**13) Мөселман ни өчен таһәрат ала?**

Җавап: намаз укырга...

**14) "Мүтә" сугышында өч хәрби җитәкче шәһид була, кемнәр алар?**

Җавап: Зәйд бин Хәрисә, Җәгъфәр бин Әбий Талиб, Габдуллаһ бин Рауәхә.

**15) Нинди эш иң хәерлесе?**

Җавап: вакытында укылган намаз.

**16) Муса фиргавенгә дагъват белән барганда иптәшкә кем барды?**

Җавап: Һәрун.

**17) Мөселманнар тулысы белән ураза тоткан айның исеме ничек?**

Җавап: Рамазан.

**18) Пәйгамбәребезгә вахи белән төшкән фәрештәнең исеме ничек?**

Җавап: Җибрил.

**19) Аллаһ мөэминнәргә нәрсә вәгъдә итте?**

Җавап: Җәннәт

**20) Җеннәр нәрсәдән халикъ кылынган?**

Җавап: уттан.

**21) Иртәнге намазның фарызы ничә ракәгать?**

Җавап: ике.

**22) Аллаһ кәферләргә нәрсә вәгъдә итте?**

Җавап: Җәһәннәм.

**23) Әгәр дә мөселман берәр нәрсәгә сокланса нәрсә әйтә?**

Җавап: мәшәАллаһ.

**24) Ни өчен мөселманнар зөльхиҗҗә аенда Мәккәгә баралар?**

Җавап: хаҗ кылырга.

**25) Пәйгамбәребезнең беренче хатынының исеме ничек?**

Җавап: Хадиҗә бинт Хуәйлид.

**26) Исламга кадәр Мәдинәдә нинди кабиләләр яшәгән?**

Җавап: әл-Әүс һәм әл-Хазраҗ.

**27) "Бәдер" сугышы кайсы айны була һәм кемнәр җиңә?**

Җавап: Рамазан аенда – мөселманнар җиңә.

**28) Пәйгамбәребезгә иң беренче булып хатын-кызлардан кем иман китерә?**

Җавап: Хәдиҗә бинт Хуәйлид.

**29) Өйлә, икенде һәм ястү намазларының фарызлары ничә ракәгать?**

Җавап: 4.

**30) Мөселман йокыдан торгач нәрсә әйтә?**

Җавап: Әлхәмдүлилләһилләзи әхйәнә бәгъдә мә әмәтәнә вә иләйһиннүшүр.

**31) Пәйгамбәребез һиҗрәт кылган шәһәрнең исеме ничек?**

Җавап: Мәдинә

**32) Фиргавен һәм аның кавеме кайда яшиләр иде?**

Җавап: Мисыр (Египет) җирендә.

**33) Аллаһ нәрсәне иң беренче халикъ кылды?**

Җавап: каләмне.

**34) Исламда иң беренче мөәзин кем иде?**

Җавап: Биләл бин Рабәх әл-Хәбәший.

**35) Зәкәт тиешле өч кешене әйт:**

Җавап: фәкыйрьләр – мескеннәр – бурычлы кешеләр.

**36) Ахшам намазы ничә ракәгать?**

Җавап: 3

**37) Мәдинә шәһәренең иске исеме ничек?**

Җавап: Ясриб.

**38) Ислам гакыйдәсенең чыганакларын әйт?**

Җавап: Коръән һәм сөннәт.

**39) Пәйгамбәребез вафат булганнан соң кем хәлиф булып калды?**

Җавап: Әбү Бәкер.

**40) Аллаһның һәм пәйгамбәрнең арысланы дигән исем кемгә бирелде?**

Җавап: Хәмзә бин Габдулмутталибка.

**41) Ни өчен фил ияләре Мәккәгә юнәлделәр?**

Җавап: Кәгъбәтулланы җимерергә.

**42) Аллаһның берлегенә ишарәт иткән аятьне әйт?**

Җавап: Ихлас сүрәсе 1нче аять.

**43) Пәйгамбәребезнең сер иясе кем?**

Җавап: Хүзәйфә бин әл-Йәмәән.

**44) Фил ияләрен Аллаһ ничек һәлак итте?**

Җавап: алар өстенә таш белән төркем-төркем кошлар җибәрде.

**45) Мохтаҗларга ярдәм итүче кеше саран буламы яки юмартмы?**

Җавап: юмарт.

**46) Җомга намазы ничә ракәгать һәм аның алдыннан нәрсә була?**

Җавап: 2 ракәгать – хөтбә була.

**47) Ни өчен пәйгамбәребезнең хаҗы "саубуллашу хаҗы" – дип аталды?**

Җавап: чөнки пәйгамбәребез бу хаҗда мөселманнар белән саубуллашты.

**48) Мөселманнар намаз укыганда кайсы тарафка юнәләләр?**

Җавап: изге Кәгъбәтуллаһ тарафына.

**49) “Фил елы”нда нинди мөһим вакыйга була?**

Җавап: пәйгамбәребез туды.

**50) Намазның барча ракәгатендә дә нинди сүрә укыла?**

Җавап: әл-Фәтихә.

**51) Мәчеттә азан әйтүче кешене кем диләр?**

Җавап: мөәзин.

**52) Пәйгамбәребезнең кызларын әйтеп уз?**

Җавап: Зәйнәб, Рукайиә, Үммү Күлсүм, Фәтыймә.

**53) Мөселман чит кеше йортына ничек керә?**

Җавап: Рөхсәт сорый һәм йорт әһелләренә сәлам бирә.

**54) Мәдрәсәнең нинди файдасы бар?**

Җавап: гыйлем бирә һәм тәрбияли.

**55) Әтисез туган пәйгамбәр кем?**

Җавап: Гайсә галәйһиссәлам.

**56) Коръән китабында тәртип буенча иң соңгы сүрә нинди?**

Җавап: “ән-Нәс” сүрәсе.

**57) “И” хәрефенә башланган берсе 4, ә икенчесе 5 хәрефтән торган ике сүз әйт.**

Җавап: Иман – Ислам.

**58) Пәйгамбәребезгә вахи кайсы тау тишегендә иңде?**

Җавап: “Хира”

**59) Пәйгамбәребезнең әтисенең исеме ничек иде?**

Җавап: Габдуллаһ бин Габдулмутталиб.

**60) Пәйгамбәребез Мәккәдә үзенең сахәбәләре белән кайда җыела торган иде?**

Җавап: әл-Әркам бин Әбий әл-Әркам йортында.

**61) Пәйгамбәребез вакытындагы сукыр мөәзиннең исеме ничек?**

Җавап: Гамр бин Үмм Мәктүм.

**62) Нәрсә ул Коръән?**

Җавап: Ул, Җибрил фәрештә аша пәйгамбәребез Мөхәммәдкә иңдерелгән Аллаһ тәгаләнең кәләме (сүзе).

**63) Кайсы пәйгамбәрне кит балыгы йотты?**

Җавап: Юныс.

**64) Ир-атлардан иң беренче булып пәйгамбәребезгә кем иман китерде?**

Җавап: әбү Бәкер.

**65) Пәйгамбәребезнең әнисенең исеме ничек?**

Җавап: Әминә.

**66) Госман бин Гаффан ничә ел хәлифлек итә?**

Җавап: 12.

**67) Халид бин Вәлид кайда күмелә?**

Җавап: Сириядагы Хумс шәһәрендә.

**68) Намазда имамга оеган кеше аның артыннан баса, ләкин кайберәүләр имамга капма-каршы басып намаз укый һәм намазлары дөрес була. Аңлатып бир?**

Җавап: Бу Мәккәдә әл-Хәрам мәчетендә Кәгъбәтулла тирәли.

**69) Тугры хәлифләрнең кайсылары 63 яшь булды?**

Җавап: Әбү Бәкер, Гомәр, Гали.

**70) Муса таягы белән ташка суккач ничә чишмә бәреп чыкты?**

Җавап: 12.

**71) Пәйгамбәребезнең сөт анасының исеме ничек?**

Җавап: Хәлимә әс-Сәгьдия.

**72) Мөселман намазга кергәндә нәрсә әйтә?**

Җавап: “Аллаһу әкбәр” – дип әйтә.

**73) Халид бин Вәлид кайсы елны Ислам кабул итә?**

Җавап: Һиҗри буенча 7нче елны, “сулх әл-хүдәйбия”дән соң.

**74) Әбү Җәһел кайсы сугышта үтерелә?**

Җавап: Бәдердә.

**75) Пәйгамбәребезнең әнисе вафат булганда аңа ничә яшь иде?**

Җавап: алты.

**76) Исламдагы беренче шәһид кем?**

Җавап: Сүмәйә бинт Хуббәтъ.

**77) Мөселман намазын ничек тәмамлый?**

Җавап: “әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ” – дип.

**78) Үзенең тормышында беркайчан да җиңелмәгән мөселман хәрби җитәкчесе кем?**

Җавап: Халид бин әл-Вәлид.

**79) Әбү Бәкер белән Гомәр кайда күмелделәр?**

Җавап: Мәдинәдә, пәйгамбәребез янәшәсендә.

**80) Һиҗри тәкъүимне кем башлап җибәрде?**

Җавап: Гомәр.

**81) Һиҗри тәкъүим буенча ай исемнәрен санап уз?**

Җавап: мөхәррәм, сафәр, рабигуль-әүвәл, рабигус-сәни, җүмәдәл-әүвәл, җүмәдәс-сәни, раҗәб, шәгьбән, рамазан, шәүүәл, зүлькагьдә һәм зүльхиҗҗә.

**82) Намаз укучы рукүгьтә нәрсә әйтә?**

Җавап: сөбхәнә раббиәль газыйм

**83) Мәзхәбләрдәге дүрт имамны әйт?**

Җавап: Әбү Хәнифә, Мәлик, Шәфигый һәм Әхмәд бин Хәнбәл.

**84) Ислам ялганга һәм золымга ничек карый?**

Җавап: Ялган белән золым Исламда тыела һәм хәрам санала.

**85) Пәйгамбәребезнең Рукайя һәм Үммү Күлсүм исемле кызларына өйләнгән сахәбәнең исеме ничек?**

Җавап: Госман бин Гаффан.

**86) Намаз укучы сәҗдәдә нәрсә әйтә?**

Җавап: сөбхәнә раббиәль әгьлә.

**87) Мөселман азанны ишеткәндә нәрсә әйтә?**

Җавап: Мөәзин артыннан кабатлый аннары догасын укый.

**88) Иртәнге намазның азаны башка азаннар белән нәрсәдә аерыла?**

Җавап: Иртәнге намаз азанына “әс-саләтү хайрум-минәннәүүм” – дип өстәлә.

**89) Казан ханлыгы явыз Иван тарафыннан ничәнче елны яулап алына?**

Җавап: 1552 елда

**90) Ни өчен Аллаһ безне халикъ кылды?**

Җавап: Үзенә гыйбадәт кылыр өчен.

**91) Ай хәрефләрен әйтеп уз?**

Җавап: ء – ب – ج – ح – خ – ع – غ – ف – ق – ك – م – ه – و - ي

**92) Ни өчен Аллаһ кешегә теш булдырган?**

Җавап: Ашарга һәм сөйләшергә.

**93) Кояш хәрефләрен әйтеп уз?**

Җавап: ت – ث – د – ذ – ر – ز – س – ش – ص – ض – ط – ظ – ل - ن

**94) Коръәндә искә алынган пәйгамбәрләр ничә?**

Җавап: 25.

**95) Фытыр садакасы кайчан фарыз булды?**

Җавап: Һиҗри буенча икенче елны, рамазан уразасы фарыз булганда.

**96) Балалардан пәйгамбәребезгә кем иң беренче иман китерде?**

Җавап: Гали.

**97) Пәйгамбәребезнең исра кылынуы хакында әйт, кайдан кая иде?**

Җавап: Мәккәдәге әл-Хәрам мәчетеннән әл-Кудстагы әл-Әкъса мәчетенә иде.

**98) Рамазан ае һиҗри ткъүим буенча ничәнче ай?**

Җавап: тугызынчы.

**99) Ни өчен мөселманнар Мәккәдән Мәдинәгә һиҗрәт кылды?**

Җавап: Ислам кабул иткәннән соң мөшрикләр тарафыннан каты иза булганга.

**100) Пәйгамбәребезнең Мәдинәгә һиҗрәт кылуында юлдашы кем иде?**

Җавап: Әбү Бәкер әс-Сыддыйк.

**101) Исламдагы беренче мәчет ничек атала?**

Җавап: Кубә мәчете.